**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлегенең Түбән Кармалка авылында

**02 ноябрь 2023 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Түбән Кармалка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Түбән Кармалка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 700 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Түбән Кармалка авылында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, триммерлар сатып алу, ротацион элмә чапкыч сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Түбән Кармалка торак авылында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Су белән тәэмин итү урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект - смета документлары өчен түләү, хезмәтләр өчен түләү) Түбән Кармалка авылында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру (ремонтлау), чүп савытларын урнаштыру, агачларны кисү, корысарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Түбән Кармалка авылында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Митякин